Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Менделеевск ш. № 39

28.01.2026

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районының мәктәпкәчә
мәгариф учреждениеләренә йөргән өчен
аерым категория ата-аналарның
(законлы вәкилләрнең) ата-ана түләве турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 65 статьясындагы 2 пункты нигезендә, балалары районның мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләренә йөрүче ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) аерым категорияләренә матди ярдәм күрсәтү максатыннан, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 1 гыйнвареннан алып 2026 елның 31 декабрена кадәр Менделеевск муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнә торган ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) аерым категорияләре исемлеген кушымта нигезендә расларга.

2. Менделеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына 0701 бүлеге буенча тапшырылган исәп-хисаплар нигезендә мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләренә акчаларны финанслауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: https://mendeleevsk.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы"нда түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ю.М.Рыбаковага йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Искаков

Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2026 елның
28 гыйнварендагы 39 номерлы
карарына кушымта

Мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә балаларны матди карап тору Менделеевск муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла торган аерым категориядәге ата-аналар (законлы вәкилләр) исемлеге

| № п/п | Категория исеме | Ата-ана түләвен киметү проценты |
|---|---|---|
| 1. | Ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) берсе 1 яисә 2 төркем инвалид булган гаилә | 100% |